СОВЕТ
БОЛЬШЕШУРНЯКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОЛЫ ШУРНЯК
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

№ 169 с. Большой Шурняк(Олы Шүрнәк) 2019 елның 18 ноябре

Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Алабуга муниципаль районы, Алабуга шәһәре һәм Алабуга муниципаль районы авыл җирлекләре бюджетына Алабуга муниципаль районы Олы Шүрнәк авыл җирлеге бюджетыннан субсидияләр бирү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.3 статьясы нигезендә, Олы Шүрнәк авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының " Алабуга муниципаль районы Олы Шүрнәк авыл җирлеге бюджетыннан Алабуга муниципаль районы, Алабуга шәһәре һәм Алабуга муниципаль районы авыл җирлекләре бюджетларына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында, әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә субсидияләр бирү турында нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны икътисади үсеш, бюджет, салымнар, тариф сәясәте, эшкуарлыкка ярдәм итү һәм туризм мәсьәләләре буенча комиссиягә йөкләргә.

Җитәкче Н.И. Мельников

Алабуга муниципаль районы
Олы Шүрнәк авыл җирлеге советының
2019 елның 18 ноябрендәге 169 номерлы
карарына 1 нче кушымта

Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Алабуга муниципаль районы, Алабуга шәһәре һәм Алабуга муниципаль районы авыл җирлекләре бюджетына Алабуга муниципаль районы Олы Шүрнәк авыл җирлеге бюджетыннан субсидияләр бирү турында
Нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә Алабуга муниципаль районы Олы Шүрнәк авыл җирлеге бюджетыннан Алабуга муниципаль районы, Алабуга шәһәре һәм Алабуга муниципаль районы авыл җирлекләренә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен (алга таба – субсидияләр) финанслашу максатларында субсидияләр бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели.
2. Субсидияләр бирүнең максаты-җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу.
3.Субсидияләр күрсәтелгән максатларга каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.
4. Әлеге Нигезләмә нигезендә бирелә торган бюджет ассигнованиеләрен Алабуга муниципаль районы Олы Шүрнәк авыл җирлеге башкарма комитеты Төп бүлүче булып тора.
5. Алабуга муниципаль районы, Алабуга шәһәре һәм Алабуга муниципаль районы авыл җирлекләре бюджетларына субсидияләрне бүлү Олы Шүрнәк авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Олы Шүрнәк авыл җирлегенең 2020 нче елга һәм 2021, 2022 нче елларның планлы чорына бюджеты турында»гы карары белән раслана.
6. Субсидияләр бирү максатлары һәм тәртибе Олы Шүрнәк авыл җирлеге башкарма комитеты һәм Алабуга шәһәре Башкарма комитеты, Алабуга муниципаль районы башкарма комитеты, Алабуга муниципаль районы авыл җирлекләре башкарма комитетлары арасында төзелә торган килешүләр белән билгеләнә.
7. Килешүдә түбәндәге төп нигезләмәләр булырга тиеш:
а) субсидияләрнең максатчан билгеләнеше;
б) субсидия бирү һәм аны тоту шартлары;
в) субсидия бирүгә каралган бюджет ассигнованиеләре күләме;
г) субсидия күчерү графигы;
д) субсидия бирү һәм тоту өчен билгеләнгән шартларның үтәлешен тикшереп тору тәртибе;
е) финанс тәэминаты чыганагы субсидия булган чыгымнарны тормышка ашыру турында хисап бирү сроклары һәм тәртибе.

8. Килешү проектын әзерләү Олы Шүрнәк авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан башкарыла һәм Алабуга муниципаль районы башкарма комитетына, Алабуга шәһәре Башкарма комитетына, Алабуга муниципаль районы авыл җирлекләре башкарма комитетларына җибәрелә.

9. Килешү Олы Шүрнәк авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе һәм Алабуга муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе, Алабуга шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе, Алабуга муниципаль районы авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан имзалана.

10. Субсидия алу өчен Алабуга муниципаль районы башкарма комитеты, Алабуга шәһәре Башкарма комитеты һәм Алабуга муниципаль районы авыл җирлекләре башкарма комитетлары Олы Шүрнәк авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан билгеләнгән вакытта, Олы Шүрнәк авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан расланган формада субсидия бирүгә гариза бирә.

11. Олы Шүрнәк авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан Алабуга муниципаль районы, Алабуга шәһәре һәм Алабуга муниципаль районы авыл җирлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең территориаль органнары счетларына субсидияләр күчерелә.

12. Субсидияләр бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Олы Шүрнәк авыл җирлеге бюджеты керемнә Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә күчерелергә тиеш.

13. Субсидияләр бирү елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына файдаланылмаган субсидияләр калдыгы Олы Шүрнәк авыл җирлеге бюджеты керемнә Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә кире кайтарылырга тиеш.

14. Башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын закон нигезендә Олы Шүрнәк авыл җирлеге башкарма комитеты һәм Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы контрольдә тота.